РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск,
423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт,
Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 15 октябре № 18

Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 14 апрелендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә гражданнар җыелышларын һәм конференцияләрен (делегатлар җыелышларын) билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 14 апрелендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә гражданнар җыелышларын һәм конференцияләрен (делегатлар җыелышларын) билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.2 пунктта «һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларын,» сүзләреннән соң «инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча фикер алышулар,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р.Метшин